# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**17 декабрь 2021 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге Уразай торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 150 сум күләмендә, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Уразай авыл җирлегендә урамнарны яктырту һәм урамнарны яктырту буенча хезмәт күрсәтү ( лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү;
- Уразай авылы мәдәният йорты коймаларын алыштыру (материаллар сатып алу, коймалар урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Уразай авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Җиңү көне», «Сабантуй»,«Балаларны яклау көне», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар көне" нә бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәтләр);
- Уразай авылында юлларны кардан чистарту;
- "Беларус 81.2" тракторын карап тоту, килешү буенча ягулык, асылмалы җиһазлар (коммуналь борылма борылыш, КУН-10 төягече )алу;
- Уразай авылындагы себерязвалы үләт базын ремонтлау.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Уразай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Уразай авыл җирлеге башлыгы (имза) А.М.Шәрифуллина (имза расшифровкасы)